# Алар Ватан өчен  көрәштеләр



**1941 ел 22 июнь… Таң атып килә. Гүзәл авыллар, шәһәрләр тыныч йокыда. Әниләрнең җылы куенында тәмле төшләр күреп нәни сабыйлар изрәп йоклыйлар. Шул вакытта канга туймас фашист этләре безнең чикләрне бозып, авылларны, шәһәрләрне үлем утына тоттылар. Бөек Ватан сугышы башланды.**

**Халкыбыз дошманны җиңү өчен бердәм булып, илне саклаучылар сафына баса. Сугышта да, тылда да беркемгә дә җиңел булмый. Барысы да җиңү таңы тизрәк атсын өчен тырышалар. Сугыштан бер-бер артлы кайгылы хәбәрләр, кара кәгазьләр килә. Әни-апаларыбыз, әбиләребез тешләрен кысып булса да түзәләр. Әниләр улларын, хатыннар ирләрен, балалар әтиләрен югалта. Фашист илбасарлары илебезнең 1710 шәһәрен һәм посёлогын, 70 меңнән артык авылын яндыралар һәм җимерәләр. Иң аянычы үзләре басып алган җирләрендә 6 миллионлап кешене җәзалап үтерәләр. 4 куркыныч ел, 1418 коточкыч көн һәм төн дәвам итә Бөек Ватан сугышы.Шулай да халкыбыз җиңүгә зур ышаныч белән яши.Бу дәһшәтле сугышта безнең авылдан 140 кеше катнашкан.**

Дошманнарны җиңәр өчен
Китәбез без Тоймадан.
Кайгырмагыз сөйгән ярлар,
Кайтырбыз без сугыштан, дип җырлап чыгып киткән булсалар да, 90 авылдашыбыз туган туфракларын яңадан күрү бәхетенә ирешә алмады. Алар еракта мәңгелек йокыга талдылар.

Туган җире, туган халкы өчен башларын салган бу батырларны онытырга безнең хакыбыз юк. Алар безнең белән, безнең арада. Безнең якты киләчәгебез, сабыйларның тыныч йокысы өчен чит җирләрдә ятып калган авылдашларыбызның якты истәлеге күңелләрдә мәңге сакланыр. Алар хөрмәтенә салынган һәйкәлгә батырларның исемнәре уелган.





# ТУГАН АВЫЛЫМНЫҢ ТУКСАН БАТЫРЫ

Туган авылымның туксан батыры
Ятып калган сугыш кырында.
Җирне иңләп, якты истәлекләр
Йөри бүген алар турында.

Күк йөзендә кояш янган чакта
Исемнәре калмас онытылып:
Һәйкәл булып авыл уртасына
Баскан алар иңгә иң торып.

Соры шинель киеп өсләренә
Сафта бара алар һаман да.
Гомерләре – якты маяк сыман,
Нурын сибә килер заманга.

Туган авылымның туксан батыры
Исәннәрнең күңел түрендә.
- Уяу булыгыз, - дип, ил улларын



Ахметшин Мөхәммәтша
Бадакшин Идиятулла
Баһаутдинов Гыйльман
Вәлиуллин  Хуҗа
Вәлиев Абзалетдин
Вәлиев Мулланур
Вәлиев Мулламөхәммәт
Вәлиев Галиәхмәт
Галиәскәров Габдрахман
Габдрахманов Фәйзрахман
Габдрахманов Бари
Гыймазетдинов Кәшфетдин
Гыймазетдинов Мәхмүтҗан
Гыйльманов Мәхмүт
Гыйльманов Йосыф



Гыйльманов Минехаҗетдин
Гыйльметдинов Минемөхәммәт
Гәрәев Минемөхәммәт
Гилязин Бари
Гыйзәтуллин Хуҗа
Гыйзәтуллин Исмәгыйль
Гомәров Нәҗип
Дәүләтшин Шәмсемөхәммәт
Дәүләтшин Фәттах
Дәүләтшин Минемөхәммәт
Диазетдинов Мифтахетдин
Закиров Минехуҗа
Зарипов Касыйм
Зиннәтуллин Минәхмәт
Зәйнуллин Фәрхетдин



Исламгулов Зиннур
Исламгулов Мансур
Исламгулов Миргаяз
Камалетдинов Галəлетдин
Кашапов Минемөхəммəт
Кашапов Вəлиəхмəт
Каюмов Габдрахман
Марданов Фəрҗəветдин
Миндрахманов Жофар
Минəхметов Шəмсемөхəммəт
Минəхметов Рəхим
Минəхметов Минемөхəммəт
Минемөхəммəтов Хаҗиəхмəт
Мифтахов Минегалим
Минегулов Хуҗа



Муллахметов Хәбибрахман
Мөхәмәтҗанов Абдулхак
Мөхәмәтҗанов Мөбәрәк
Мөбәрәкшин Нәкыйп
Нурмөхәмәтов Рифкать
Нәҗмиев Мулланур
Нәҗмиев Мулламөхәммәт
Нәбиев Габдулла
Нәбиев Динмөхәммәт
Нигъмәтуллин Әхмәтхан
Нигъмәтуллин Рамазан
Насифуллин Зиннур
Насифуллин Касыйм
Нәбиуллин Галиәхмәт
Нәбиуллин Сәмигулла





**Рәхимов Габдрахман**
**Рәхимов Нигъмәтҗан**
**Сабирҗанов Галимҗан**
**Сабирҗанов Сәетҗан**
**Сабирҗанов Шәрифҗан**
**Садыйков Закир**
**Садыйков  Мингариф**
**Сәләхов Галәветдин**
**Ситдыйков Хөрмәтулла**
**Тимеркәев Фәйзрахман**
**Ульданов Габдулла**
**Фастахов Нәкыйп**
**Фәйзуллин Шәрифҗан**
**Хисаметдинов  Фәрәхетдин**
**Хуҗин Касыйм**




**Хуҗин Миңнулла**
**Хөрмәтуллин Миргази**
**Шакиров Шаһзада**
**Шакиров Җиһангир**
**Шаһабетдинов Бәдретдин**
**Шаһабетдинов Гәйфетдин**
**Шәйдуллин Сибгатулла**
**Шәймәрданов Хаҗи**
**Шәрәфетдинов Габдулла**
**Шәрәфетдинов Фәрҗәветдин**
**Шияпов Нәҗип**
**Җамалиев Хәйрулла**
**Җамалиев Шәмигулла**
**Җәмилев Шәмсемөхәммәт**
**Җәләлетдинов Шәйхелислам**



Ахметшин
Харис





## Фазлиев Әгъзәм





Шагабутдинов Ямалетдин





**Шакиров Файзелхак**






# Шакиров Сабир





Тимеркаев
Нәжип





# Ахунов Әптүл





**Биктимеров Гатуф**





**Бадретдинов Шаһаби**





# Биктимеров Гайсә





**Габдрахманов Габденур**





**Гильманов Гильмулла**





**Гимазиев Габтулла**





# Димухаметов Раил





# Зарипов Харис





Камалиев Миннәхмәт





## Миндрахманов Лотфи





Заляев Минемөхәмәт





# Насифуллин Касыйм





**Ситдиков Мөхәмәтхан**





# Ситдиков Минехан





## Ситдиков Мөхәмәтнур





**Хабибрахманов Фәйзи**





Хузин
Рафаил






**Садыков Шакир**





# Садыков Фатыйх





# Уразманов Минегали




**Яшибез гел шулай кояшка**
**Һәм тыныч көннәргә сөенеп.**
**Һәркемнең күңелендә бер теләк:**
**Иминлек! Иминлек! Иминлек!**

**Сугыш - кешелек өчен зур фаҗига, һәр сугыш үлем, бәхетсезлек, ятимлек китерә. Сугыш афәтен башыннан кичергән кешеләр кабат сугыш булуын беркайчан да теләмәсләр. Илебез халыклары һәрчак сугышка каршы. Шулай да җир шары әлегә тыныч түгел. Дөньяның төрле төбәкләрендә сугышлар булгалап тора.**

**Сугыш кабатланмасын,**
**Гомерләр өзелмәсен!**
**Туплар атылмасын,**
**Бишекләр ватылмасын.**
**Җирләр янмасын,**
**Булмасын ла иде бу тормышта**
**Гаделсезлек,михнәт,кайгылар.**
**Яз гөлләре булып чәчәк атсын**
**Күңелләрдә иң саф тойгылар.**
**Бар булганны саклыйк кадер белән.**
**Комсызланмыйк, теләп артыгын.**
Сорыйк жиргә еллар имнлеге





Шайдуллин Хафиз

ВЕЧНАЯ ПАМЯТЬ!

